КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.08.2022 г. Казань № 257-П

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Екатерина бистәсе авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

В соответствии с Федеральным законом от 25 июня 2002 года № 73-ФЗ «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан», постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 12.07.2018 № 565 «Вопросы Комитета Республики Татарстан по охране объектов культурного наследия» приказываю:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Әлеге боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Екатерина бистәсе авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Әлеге боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Екатерина бистәсе авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) объектының территориясе чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

3. Әлеге боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Екатерина бистәсе авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) объектының территориясеннән файдалану режимын расларга.
4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Бердәм күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә.
5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М.Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис вазифаларын башкаручы Н.В. Прохорова

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының
«23»_08__2022 № 257-П
боерыгына 3 кушымта

Татарстан Респубикасының Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Екатерина бистәсе авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) объектының территориясеннән файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча эшләр башкару мөмкинлеген күздә тота.